وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# Дин вә Мәгыйшәт

№4 (101). 9 сентябрь 2011 / 11-шәүвәл-1432

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Татарстан мөселманнары митингка чыкты ▷2◁



Фестивале бар, киносы... юк ▷3◁



Казанда троллейбус пассажирларын "шәһидләр һәм шәһидәләр"дән сак булырга чакыралар ▷4◁

## Ислам террорчылыкка каршы!

***5 сентябрь көнне башкалабызның С.Сәйдәшев һәйкәле янындагы мәйданда "Ислам террорчылыкка каршы" дип исемләнгән митинг үткәрелде. Татарстан Диния нәзарәте Мөселман яшьләре берлеге белән бергәләп уздырган бу әһле ислам өчен мөһим чарада биш йөздән артык кеше, шул исәптән Казандагы, республикабыз районнарындагы дин әһелләре катнашты.***



Ислам диненең төп нигезе (мөселманны мөселман иттереп күрсәтә торган әйбер) – ул да булса пәйгамбәребез (с.г.в.) хәдисендә әйтелгәнчә: "Мөселман шундый булырга тиеш: аның кулыннан да, теленнән дә, хәрәкәтләреннән дә мөселманнар һәм башка кешеләр имин булырга тиеш". Әгәр дә төрле-төрле җинаятьләрне, ниндидер милләткә (конфессиягә) яисә ниндидер дингә бәйләп күрсәтәләр икән, бу, әлбәттә, шушы милләтне (конфессияне) мыскыл итү дигән сүз. Кечкенә генә бер җинаять булса да, бүгенге көндә аны ислам диненә яисә мөселманнарга бәйләү бара. Юк! Мөселманнар бервакытта да кешегә зарар китерергә дигән фикерне алга куймады. Мондый фикер аларның башларына да килмәде. Бәлки, мөселманлыктан ерак булган кешеләр шушындый әшәкелекләрне эшләгәндер. Бәлки наданлык яисә авыру белән кылынгандыр бу. Монда аның ниндидер амбициясен тормышка ашыра алмау да сәбәп булырга мөмкин. Әмма Аллаһы Тәгаләнең дине ярдәмендә илебез мөселманнары һәрвакытта да иминлектә, төзеклектә, прогресста, ягъни алгарышта булды. Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгалә төрле-төрле җинаятьләрне кылу сәбәпле бу дөньядан киткәннәрнең рухларын шат кылса иде. (Безнең кавемгә исә төрле-төрле шушындый җинаятьләрдә катнашкан кешеләрне туры юлга бастыр, дип һәрдаим догада булу насыйп булса иде).

Террорчылык – ул дәүләтнең һәм җәмгыятьнең җимерелүенә китерә торган иң зур җинаятьләрнең берсе, кешеләрне куркыту, газаплау булып тора.

Бер генә дин дә, кешене рәнҗетергә, кимсетергә, үтерергә өндәми. Барлык диннәрдә дә бу гамәлләр зур гөнаһ булып санала. Аллаһ Раббыбыз, кешеләрне хисап кылучы "Мин" ди һәм беркемнең дә бүтәннәрне кимсетергә, аны җәзаларга хакы юк. Кеше үтерү, аны хурлау, мәсхәрәләү – ул Аллаһы Тәгаләгә, аның хөкемнәренә каршы бару. Берәүнең дә үз-үзен үтерергә хакы юк. Бу эшләрне башкарган бәндә имансыз була һәм аның урыны – Аллаһның мәңгелек газабы. Аллаһы Тәгалә Корьәни-Кәримнең "Әнгәм" сүрәсенең 151 нче аятендә: "Аллаһ дөньяга яраткан бәндәләрне үтермәгез, җәберләмәгез", – диде.

Бесланда гөнаһсыз сабыйларның каны коелуы безнең өчен файдага түгел, аның белән дәрәҗәбезне дә үстерә алмыйбыз. Без аның исламга каршы оештырылган ялган һәм яла икәнлеген күрсәтергә тиешбез. Бу сүзләрем аклану түгел. Ә шулай да башкаларның канын коючыларны һич кенә дә мөселман дип атарга тел әйләнми. Андый бәндәләр мөселман да була алмый. Киресенчә, хак мөселман кешеләр арасында җылы мөнәсәбәт булдырырга омтыла, чөнки ул Аллаһның ризалыгын алу өчен тырыша. Мөселманнар кулыннан кан-кардәшләр генә түгел, башка халыклар да имин, сау-сәламәт булырга тиешләр. Дөрес, әһле ислам беркайчан да кешеләргә зыян салу уе белән йөрмәде. Әгәр дә без Аллаһы Тәгалә риза булмый торган гамәлләр кылсак, Аның җәзасына, башка халыкларның начар мөнәсәбәтенә юлыгуыбыз ихтимал.

Безнең һәрбер адымыбыз, һәрбер сөйләгән сүзебез һәрвакытта да кешеләргә файда китерергә тиеш. Бездән Аллаһы Тәгалә риза булырга тиеш. Әлбәттә, җинаятьләрдән Аллаһы Тәгалә риза түгел! Әлбәттә, кешене мыскыллаудан Аллаһы Тәгалә риза түгел! Әлбәттә, кешенең малына, канына, җанына кул сузудан Аллаһы Тәгалә риза түгел! Ислам дине андыйга чакырмый. Ислам дине – берләшеп, бергә булып, Аллаһы Тәгалә риза булырлык гамәлләрне бу дөньяда кылырга чакыра. Аллаһы Тәгалә риза булса, Адәм балалары да риза булыр. Аллаһы Тәгалә шул вакытта риза булмас, Риза булмаган очракта. Әгәр дә без Аллаһы Тәгалә Адәм балалары риза булмаслык дәрәҗәдә эшләр эшлибез икән, димәк, Аллаһы Тәгалә дә риза булмас.

**Үзәкләшкән дини оешма –**
**ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе,**
**мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ**

## Гошер сәдакасын мәдрәсәләргә бирик!

***Аллаһы Тәгалә тәннәребезне пакьләү өчен ураза гыйбадәтен яралткан булса, малларыбызны пакьләү өчен безгә зәкятне фарыз итте. Раббыбыз адәм баласына рухи чистарыну гына түгел, ризыгының да хәләл булуын бурыч итеп йөкләде.***



Иллә мәгәр адәм баласы үзенең җанын-рухын иман белән ныгытса, тәнен ураза белән чистарткан булса, аңа шулай ук үзенең хәләл көчләре белән тапкан малын да пакьләү фарыз ителде. Без беләбез: элек-электән газиз әти-әниләребез, әби-бабаларыбыз көз айлары җитеп, ел дәвамында үстергән үсемлекләрдән, җыеп алынган уңышлардан гошер сәдакаларын чыгару-бирү хакында күпләребезгә өйрәтеп калдырган.

Нәрсә соң ул гошер сәдакасы? Нинди гамәл ул? Адәм баласына аның нинди файдалары бар? Шул хакта танышып китик.

Хөрмәтле дин кардәшләребез! 2011 елны Аллаһы Тәгалә бәрәкәтле итте. Игенчеләребезгә, бакчачыларга һава торышы уңай килде. Аллаһның рәхмәте киң: Ул ел башын яңгырлар белән нигъмәтләндерде (үсемлекләрне чәчкәч үк безне җылы яңгырлар белән шатландырды), шуннан соң кояшлы көннәрен дә бүләк итте. Бакчаларыбыздагы уңышларны түкми-чәчми җыеп алдык, хәзер аның файдасын күрә башладык. Күпләребез инде авылларга кайтып бәрәңгеләрен дә алып килде. Без һәрвакытта да Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгаләнең биргән нигъмәтләренә шөкерана кылырга тиешбез. Чөнки бер Аллаһ кына бирүче, безне нигъмәтләндерүче. Без Аңа карата булган ризалыгыбызны ничек белдерәбез соң? Әлбәттә, Аның кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып. Көз айларында мөэмин-мөселманнарга бер бурыч йөкләнде: ул да булса гошер сәдакасын тапшыру. Татар галиме Әхмәтһади Максуди үзенең "Гыйбадәтел исламия" китабында: "Гошер бирү фарыздыр. Гошер малларының нисаблары юктыр", – дип яза. Кеше, нинди генә байлыкка ия булуга да карамастан, үзе җыеп алган уңышлардан гошер чыгару мәҗбүри булыр.

Нәрсә соң ул гошер? Гошер – ул җирдән җыеп алынган уңышның зәкяте. Ә зәкят бирү исә ислам диненең өченче баганасы. Бу гамәлне инкарь итүче кеше, әлбәттә, кяфер була. Ә инде аны ниндидер сыйфат, әйтик, саранлык белән үтәмәүче кеше зур гөнаһлы булыр. Аллаһы Тәгалә "Бакара (Сыер)" сүрәсенең 277 нче аятендә безгә шундый бер нәсыйхәтен җиткерә: "Иман китереп изге гамәлләр кылучы, намазларын укып, зәкәтләрен бирүче мөэминнәрнең әҗере Раббылары хозурында. Аларга ахирәттә курку һәм көенү булмас" (Ногмани тәфсиреннән). Ягъни шушы гамәлләрен башкарган кеше Кыямәт көнендә бернинди дә курку-көенүне күрмәс, ди.

Без, җирдә яңгыр суы белән үскән уңышның уннан берен (үзең су сибеп үстергәннең егермедән берен) фәкыйрьләргә бирергә тиеш булабыз. Бу – барыбыз алдында да зур гамәл-гыйбадәт булып тора, без шул сәбәпле генә малларыбызны пакьли, ризыкларыбызны чистарта алабыз. Әгәр дә кеше гошер бирмәсә, үзе үстереп ашаган ризыгының һәр унынчы кисәге (чөнки ул мохтаҗлар өлеше) хәрам була. Аллаһы Тәгалә һәрбарчабызны да хәрам ризыклар ашаудан сакласа иде.

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

## СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

**Аллаһы Тәгаләгә мактауларыбыз булса иде.**

**7 сентябрь көнне илебез коточкыч фаҗига кичерде – Як-42 очкычы Ярославль өлкәсенең "Туношна" һава аланыннан күккә күтәрелгәндә ватылып килеп төшеп, кырыктан артык кеше һәлак булды.**

**Якыныңны югалту - һәркем өчен дә иң авыр хәсрәтләрнең берсе. Үлем котылгысыз һәм ул барызгада дә киләчәк. Көчле, гайрәтле яшьләрнең үлеме үтә дә кызганыч.**

**ТР мөселманнары Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән илебез өстенә төшкән әлеге тирән кайгы һәм зур югалту ачысын бүлешәм, Аллаһы Тәгаләдән вафат булганнарның туганнарына сабырлык һәм түземлелек бирүен сорыйм.**

**Аллаһы Тәгалә барыбызга да рухи ныклык насыйп итсен һәм шушы авыр минутларда да Үзенең ярдәменнән ташламаса иде.**

**Үзәкләшкән дини оешма –**
**ТР мөселманнары Диния**
**нәзарәте рәисе,**
**мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ**

# Татарстан мөселманнары митингка чыкты

**Казан үзәгендә йөзләгән мөселман террорчылыкка каршы булуларын митингка җыелып белдерде.**

5 сентябрь көнне сәгать көндезге унберләр тирәсендә башланган митинг бер сәгатьләп дәвам итте. Әлеге чара "Экстремизмга юл юк!" айлыгы кысаларында үткәрелде.

Митингта Татарстан мөфтие, Диния нәзарәте рәисе Илдус хәзрәт Фәиз, Мөселман яшьләре берлеге активистлары, мөфтият, Казан епархиясе вәкилләре, дини һәм дөньяви уку йорты студентлары катнашты. Чарада катнашучылар "Мөселман яшьләре тынычлык һәм иминлек яклы", "Мөселманнар көч куллануга каршы", "Ислам – тынычлык дине" кебек плакатлар белән чыккан иде.

Митинг җәмәгатьчелекнең, аерым алганда, яшьләрнең террорчылыкка карата игътибарын җәлеп итү, кешеләргә исламның җәмгыятьтә толерантлыкны тәэмин итүче, рухи кыйммәтләргә ия булган тынычлык һәм игелеклелек дине булуын аңлатудан гыйбарәт булды.

Әлеге чара "Axelle", "Libertas" рэп төркемнәренең чыгышлары белән башланып китте. "Axelle" төркеме "Ислам террорчылыкка каршы" исемле яңа җырын тәкъдим итте. Казан шәһәре казые Мәхмүт хәзрәт Шәрәфетдин Коръән аятьләре укыды.

Мәгълүм булганча, 2004 елның 1 сентябрендә Төньяк Осетиядәге Беслан шәһәрендә террорчылар 1 нче мәктәп укучыларын чолганышка алган иде.

"Без бу куркыныч фаҗигане һәрвакыт истә тотабыз", – дип белдерде Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз журналистларга биргән әңгәмәсендә. – Мөселман яшьләре белән тыгыз элемтәдә тормасак, күп нәрсәне югалтуыбыз бар. Митингка чыгуыбызның төп максаты – мөселманнарның бердәмлеген күрсәтү". Аның сүзләреннән аңлашылганча, митингта Казан уку йортларында укучы яшьләр генә түгел, республикабызның бүтән шәһәр вузларында укучы студентлар да катнашкан. Әлмәттән, Түбән Камадан да яшьләр бар иде. Казан епархиясенең яшьләр белән эшләү бүлеге җитәкчесе Александр Хохлов Бесландагы бәлане күп кенә милләт һәм дин вәкилләренең дә истә тотуын билгеләп узды. "Башкаларга булган ихтирамны бернинди байлык та алмаштыра алмый", – дип ассызыклады ул.

Митинг азагында Бесланда һәлак булучыларны бер минут тынлык белән искә алдылар һәм алар рухына дога кылынды.

***Алинә БИКМУЛЛИНА.***
***Электрон мәгълүмат чаралары хәбәрләре файдаланылды***






# Бер генә дин дә террорчылык белән янәшә була алмый!

***Беслан фаҗигасе безнең илебез тарихына гына түгел, дөнья тарихына да иң явыз, иң мәкерле террактларның берсе булып кереп калды. Җиде ел вакыт узды, ләкин күңелдәге яралар һаман да төзәлми. Бу фаҗигале көннәрдә тоткын булып алынган 1100 кешенең, аларның якыннары, туганнарының хәләтен күз алдына да китереп булмый. Балаларының үле гәүдәләре янында үкси-үкси елаган аналар образын Россия беркайчан да онытмаячак.***

Бу терактның кешелексезлеге турында күп язылды-сөйләнде. Балаларның Белем бәйрәмен кан, күз яше белән чылатучыларны, чабып, качып баручы сабыйларга арттан атучыларны ерткычлар дип кенә атап була. Бу – дөнья тарихында тиңе булмаган ерткычлык һәм бу көннәрне искә төшергәч әле дә күңел тетрәнә.


Ләкин бу ерткычлар тагын бер явызлык эшләде… Аллаһы Тәгаләгә каршы, миллиардтан артык булган һәрбер мөселманга каршы иде бу теракт – алар үзләренең ерткычлыкларында ислам сүзен катыштырырга җөрьәт иттеләр. Бу – безнең җәмгыятьне бүлгәләү, илебездәге төрле дин һәм милләт кешеләрен каршы кую, гасырлар буе тыныч-тату яшәгән халыкларны аеру өчен эшләнде. Аллаһнын саф дине, пәйгамбәребез Мөхәммәт (с.г.в.) васыяте, дөнья цивилизациясенең бөек гуманистлары булган Җәләлетдин Руми, Ганҗәви Низами, Галишер Нәваи, Кол Галиләрнең дине турында бу ерткычлар авызыннан сүз ишетү барлык мөселманнарның күңелен рәнҗетте, йөрәкләрдә авыр йөк булып калды.

Җиде ел узгач, без инде ышаныч белән әйтә алабыз: бу – мөселманнарга карата юнәлдерелгән теракт иде! Ислам динен бетерергә, җәмгыятьтә безне изгойлар итеп күрергә теләделәр. Ләкин Аллаһның рәхмәте белән бу максатларына ирешә алмады, Россия җәмгыяте бу сынауны үтте, теракт кылучыларны динсез, милләтсез ерткычлар дип әйтергә үзебездә көч таптык. Безнең илебездә меңләгән халыклар, дистәләгән дин вәкилләре тату, дустанә мөнәсәбәттә яши, кемнәргәдер бу, әлбәттә, ошамый. Халыклар, диннәр арасында да төрле чорлар булган, ләкин беркайчан да гөнаһсыз сабыйлар ут эчендә калмаган. Без, мөселман яшьләре, бу ерткычларның ислам диненә һәм, гомумән, кеше дип аталырга хокуклары юк, дип белдерәбез! Без ата-бабаларыбыз кебек илебезгә хезмәт итеп тыныч тормышта яшәргә телибез! Террорчылыкка, халыкара, динара нәфрәткә безнең арада урын юк! Бер генә дин дә террорчылык белән янәшә була алмый! Динне, милләтне террорчылыкта гаепләү билгеле бер максаттан чыгып эшләнә. Бу максатның чынга ашуына, җәмгыятьтә динара низагларга юл куймау безнең максатыбыз!

***Айнур СОЛТАНОВ,***
***Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең яшьләр белән эшләү бүлеге җитәкчесе***

# *Казан кино фестивалендәге бердәнбер Татарстан фильмы*

**VII Казан халыкара мөселман кино фестиваленең конкурс программасына Татарстаннан бер-дәнбер фильм – Николай Морозовның "Тукай белән илһамланып" дигән фильмы кергән. Фильмның төп герое – безнең замандашыбыз, "La Primavera" Казан дәүләт камера оркестрына нигез салучы һәм аның алыштыргысыз җитәкчесе Рөстәм Абязов. Фильм ТР Мәдәният министрлыгы ярдәме белән төшерелгән һәм татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулуга багышланган.**



Әлеге фильмда Тукайның могҗизалы шигъри дөньясы үзенең чагылышын музыкада таба. Фильмның нигезен "La Primavera" оркестрының репетициясеннән алынган документаль кадрлар тәшкил итә. Биредә Рөстәм Юныс улының "Тукай" сюитасы өстендә музыкантлар белән эшләвен, оркестрантларга татар шагыйренең тормышыннан эпизодлар китерүен, шигырьләреннән аерым юлларны укуын күрергә мөмкин...

Фильмның тасвири ягын туган як табигате тулыландыра. Гадәти булмаган алымнарның берсе - тамашачы алдында комнан "тере" картиналар барлыкка китерү. Әйтерсең лә, тылсым таягын изәү белән, кадрда әле авыл күренеше, әле дирижёр сурәте барлыкка килә... "Тукай белән илһамланып" фильмында Россия һәм чит ил композиторлары музыкасы кулланыла.

***etatar.ru сайтыннан алынды***
***(Алинә БИКМУЛЛИНА тәрҗемәсе)***

# Яңа китап: "Ислам дине бүгенге көндә"

("Ислам сегодня")


***"Иман" нәшриятында Вәлиулла хәзрәт Якуповның "Ислам дине бүгенге көндә" дип аталган яңа китабы дөнья күрде. Китап 392 биттән тора. Автор үзенең яңа хезмәте турында менә ниләр сөйләде:***

– Хәзерге вакытта ислам дине динамик үсеш периоды кичерә, ул глобаль үлчәмдәге авырлык, авторитет һәм тәэсир ала.

Бигрәк тә әлеге процесс Россия, Татарстан мисалында үзенчәлекле. Ислам дине ныклы рәвештә иҗтимагый-сәяси тормышның үзәгендә булып, безнең көнкүрешебезне төрле яклап колачлый. Үткән ике дистә ел исә яңа ислам институтлары төзү чоры булды. Безнең күз алдыбызда сизелерлек дәрәҗәдә мөселман инфраструктурасы һәм башка яктан да актив рәвештә алга омтылучы, шул исәптән, интеллектуаль яктан да җанлы булган ислам оешмалары оешты.

Шулай итеп, бүгенге көндә ислам дине дөньяда, Россиядә, Татарстанда – ул динамик рәвештә үсүче феномен. Әлеге динамика тулысынча позитив характер йөртә. Өммәтебезнең хәләте – барыбызның да тырышлык нәтиҗәсе ул. Әлеге фидакарьлек аеруча нәтиҗәле булсын өчен, ситуацияләрне – ислам дине хакындагы уй-фикерләрнең кичәгесен һәм бүгенгесен анализлау мөһим. Моннан чыгып исә динебезнең киләчәктә нинди булачагын да фаразларга мөмкин булачак. Китап бүгенге көнне һәм киләчәкне өйрәнүгә багышланган.

***muslem.ru сайтыннан алынды***



## Рөстәм МИҢНЕХАНОВ:

# "Казан үзәгендә тәртип урнаштырырга кирәк"

***Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов шәһәр төзелеше кодексын бозуларга, башкаланың тарихи өлешендә республика башкаласының тышкы күренешен бозучы күпкатлы йортлар төзүгә юл куймас өчен, ТР Дәүләт архитектура-төзелеш күзәтчелеге инспекциясенә Казанның тарихи үзәгендәге барлык төзелеш объектларын тикшерергә күрсәтмә бирде. Республика башлыгы фикеренчә, Казан үзәгендә гап-гади тәртип урнаштырырга, урамнар һәм иске биналарның эчке ишегалларындагы чүп-чарны җыештырырга кирәк. 3 сентябрь көнне Рөстәм Миңнеханов Тукай, Париж Коммунасы, Мәскәү (элеккеге Киров) урамнары буйлап җәяүле экскурсия ясаганнан соң әнә шулай дип белдерде.***



Маршрутны Казан экскурсоводы, Бөтенроссия тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне саклау җәмгыятенең Татарстан бүлеге советы әгъзасы Олеся Балтусова эшләде.

Татарстан башлыгы өчен экскурсия Тукай урамындагы 14 нче йорт яныннан башланды. Колхоз базарына илтүче әлеге урамда күп кенә ташландык-иске йортлар урнашкан, аларда торыр урыны булмаган кешеләр, шулай ук эмигрантлар яши. Урамның бер ягында күп кенә йортлар сүтелгән, ә Тукай тыкрыгында Казандагы бердәнбер керәшен чиркәве урнашкан.

Рөстәм Миңнеханов Шакир солдат йортын, иң эре мөселман уку йортларыннан берсе булган "Мөхәммәдия" мәдрәсәсен карады.

Олеся Балтусова Рөстәм Миңнехановның игътибарын округта күп кенә кунакханәләр урнашуына һәм туристларга тәрәзәләрдән күңелсез күренеш ачылуына юнәлтте. Өстәвенә, Казанга килүче күп кенә туристлар нәкъ менә борынгы Казан буйлап экскурсияләргә бик теләп заказ бирә, Иске Татар бистәсендәге азкатлы йортларның ишегалларына керергә ярата. Шундый сакланып калган ишегалларның берсе – XX башында төзелгән, милли баш киемнәре (кәләпүшләр) тегү остасы Гайнетдин Сабитов йорты.

Иртәнге як булуга да карамастан, әлеге йортта яшәүчеләр ТР Президенты белән аралашырга чыкты. Йортта 14 фатир һәм бер кафе урнашкан. Биредә яшәүчеләр үз йортларын капиталь ремонт программасына кертмәүләренә зарланды, янәсе, бу "рентабельле түгел".

Алга таба экскурсия маршруты "XIX йөз ахыры - XX йөз башында төзелгән Кәримовлар китап бастыру фирмасы биналары комплексы", "1983 елда төзелгән сәүдәгәр Вәли Яушев йорты" аша узды – әлеге биналарның барысы да архитектура һәйкәлләре санала.

Париж Коммунасы урамында шулай ук "Нурулла" ("Печән базары") мәчете (биналар комплексы), урамның каршы ягында "И.И.Апаков йорты – XIX йөз уртасы архитектура һәйкәле" урнашкан.

Олеся Балтусованың сүзләренә караганда, өлешчә үзенең көнчыгыш колоритын саклап калган әлеге урамга туристлар күпләп килә – биредә хәләл ризыклар әзерли торган кафе, мөселман киемнәре салоны урнашкан.

Мәскәү (элеккеге Киров) урамындагы бер бинага Үзбәк милли-мәдәни мохтәрияте реставрация үткәргән, ул биредә икенче һәм өченче катларда урнашкан. Аңа Казан университеты профессоры Карл Фукс яшәгән җимерек бина терәлеп тора. Әлеге йорт шулай ук тарихи һәйкәлләрдән санала.

Мәскәү һәм Столбов урамнары арасындагы бакча экскурсия маршрутының соңгы объекты булды.


Экскурсия тәмамланганнан соң Рөстәм Миңнеханов аның өчен Казанның тарихи өлеше буйлап берничә җәяүле маршрут әзерләргә кушты. "Без соңга калырга мөмкинбез һәм тагын берничә елдан соң шәһәрнең тарихи өлешеннән берни дә калмаячак", – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов һәм Олеся Балтусова белән экскурсиядә шулай ук ТР Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Ирек Фәйзуллин, ТР Эчке эшләр министры Әсгать Сәфәров, Татарстан Республикасы прокуроры Кафил Әмиров һәм башкалар булды.

***ТР Президенты матбугат хезмәте***
***Фото prav.tatarstan.ru сайтыннан алынды***

# ФЕСТИВАЛЕ БАР, КИНОСЫ... ЮК

**Казан Халыкара мөселман кино фестиваленең конкурс программасына Татарстаннан бер генә фильмның сайланып алынуы шаушу кузгатты бугай. Кемнәрдер кырык иләктән үткәрүче жюри төркеме татар мохитен, аның яшәешен аңламый дигән фикер үткәрде, кемнәрдер акча капчыгының сай булуына сылтап калдырды. Кайберәүләр, "Бибинур"ны кабатларлык башка татар фильмы тумаячак, дип фаразлады.**




Ни өчен нәфис фильмнарны быел конкурстан тыш программада гына карыйбыз соң? Ә документаль һәм нәфис фильмнар төшерелгән ләбаса. Салават Юзеев, Рамил Төхфәтуллин, Дмитрий Тарханов, Дамир Барышевларның иҗат җимешләре туган бит әнә! Аларны тамашачы "Татарстанда төшерелгән фильмнар" дигән исем астында билгеле бер көндә карый алачак. Шулай ук Үзбәкстанда төшерелгән фильмнарга да билгеле бер вакыт каралган.

Режиссёр Рамил Төхфәтуллинның Казан халыкара мөселман кино фестивалендә беренче генә катнашуы түгел инде. Быел тамашачы аның "Алтын шимбә"сен карый алачак, әмма конкурстан тыш программада. Фильмның ни өчен сайлап алу комиссиясе аша үтмәвен ул үзе дә аңлый алмый.

– Минемчә, фильмнар жюри рәисенең зәвыгына карап сайлап алына, – ди Рамил әфәнде. - Ә мөселман кино фестиваленең жюри рәисе, һичшиксез, мөселман кешесе булырга тиеш. Конкурска үтмәгән фильм хакында кызыксынгач, төшерелгән фильмыгыз фестиваль кысаларына туры килмәде, диделәр. Күрәсең, фильм дини, милли темаларны үз эченә алмагандыр. Бәлки...

"Ә заманында дини, милли темаларны киң яктырткан "Зөләйха"ны фестивальгә алмадылар түгелме?" – дип сорыйм режиссёрдан.

– Әйе, ул вакытта бу фильмны караганнан соң үзара низаг чыгарга мөмкин, диделәр.


Шамил АБДЮШЕВ

Артык дини темага бирелергә дә, шул ук вакытта фәлсәфә куертмыйча даими яшәешне дә чагылдырырга ярамый, ә фәкать алтын урталыкны гына таба белергә кирәк. Күрәсең, безнең мохиттә кино тудыру өчен ниндидер мөгез чыгарырга кирәктер. Рамил Төхфәтуллин күптән инде Мәхмүт Галәүнең "Мөһаҗирләр" әсәре буенча фильм төшерергә тели икән. "Ә аны җиренә җиткереп башкару өчен дәүләт ярдәменнән башка булмый", - ди ул.

Дәүләтнең кинематографиягә бүлеп биргән акча янчыгы исә ел саен саега бара. "Кызык инде бездә: фестивалебез бар, ә кинобыз юк", – ди Рамил Төхфәтуллин.

Тагын шунысы да бар: бездә үзең теләгән теләсә нинди темага фильм төшереп булмый. Цензура башыңа баса. Ни өчен мөселман илләренең гадәти яшәеше, көнкүреше турындагы фильмнары конкурс программасына кертелә соң, дигән сорауга менә шуннан чыгып җавап бирергә кирәктер, мөгаен. Мөстәкыйль илнең кинематография өлкәсенә җаваплы һәм төшереләчәк фильмга чын сәнгать әсәре итеп каравы да бик мөһим роль уйный.

Юк, Татарстан режиссёрларын мактарга да, акларга да җыенмыйм. Безгә Иран, Төркия, Америка, Германия илләре кебек гадәти яшәештән менә дигән фильм төшерү өчен кырык тапкыр казанда кайнап чыгарга кирәк. Алай дисәң, күрше Башкортстанда да менә дигән фильмнар туып ята икән ләбаса. Фестивальнең беренче көнендә Булат Йосыповның "13 нче раунд" фильмын карарга туры килде. Режиссёр әйтүенчә, фильмның премьерасын Башкортстанда 26 августта күрсәткәннәр. Режиссёр конкурстан тыш программада Казан тамашачысына әлеге фильмын күрсәтергә дә өлгерде. "Миңа бит конкурста катнашу иң мөһиме түгел, ә сезнең тәэсирне күрү, сезнең фикерне ишетү бик кирәк", - диде ул.

Күрше республикадагы режиссёрның фикере күпләргә ошады. Ул кайберәүләргә киноның ниндидер бәйгеләрдә урын яулау өчен төшерелмәвен ассызыклап китте.

Кичә фестивальнең конкурстан тыш программасында тамашачы шулай ук Иран, Үзбәкстан, Казахстан, Әзәрбайҗан фильмнарын да карады. Алай гына да түгел, ике көн дәвамында яшь режиссёрларыбыз да көч сынашты әле. Фестиваль кысаларында инде өченче тапкыр Казан халыкара һәвәскәр һәм яшьләр киносы фестивале уздырылып килә. Элек катнашучылар Россиядән генә булса, быел Украина һәм Казахстан да килеп кушылган. Гран-при иясенә 50 мең сум күләмендә акча бирелә. Фестивальнең иң яшь режиссёры исә IV сыйныфта гына укый икән. Режиссёрларыбыз, үз операторларыбыз юк, шуңа күрә читтәгеләрне чакырырга мәҗбүрбез, дип зарлана идек, димәк, әкренләп кадрлар әзерли башладык кына әле. Алдагысы, кем әйтмешли, Аллаһы Тәгалә кулында.

***Алсу ХӘСӘНОВА.***
***vatantat.ru сайтыннан алынды***

# Гошер сәдакасын мәдрәсәләргә бирик!

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) бер хәдисендә: "Әгәр дә кешеләр үлчәүдә хыянәт итсәләр – тормышларында авырлык күрерләр, азанга игътибар итмәсәләр – тынычлык тапмаслар, тиешенчә (Аллаһ кушканча) киенмәсәләр (гаурәтләрен капламасалар яисә зинаны ачыктан-ачык кылсалар) – Аллаһы Тәгалә аларга күз күрмәгән, колак ишетмәгән авырулар җибәрер, тиешле зәкят-гошерләрен бирмәсәләр – яңгырны вакытында яудырмас (яңгыр яуса да, үсемлек-хайваннар хакына булыр)", – диде.

Бу дөньяда адәм баласы үзенә бирелгән малның Аллаһы Тәгаләдән булуын оныта. "Үзем таптым, үзем тырышлык куйдым, эшләдем", – ди, мәгәр, эшләсә дә, бирүчесе Аллаһ Раббыбыз икәнлеген онытып җибәрә. Аллаһы Тәгалә үз дөньясы белән генә яшәгән, Аллаһ биргәннәрдән өлеш чыгармаган бәндәләр хакында "әл-Гыймран" сүрәсенең 180 нче аятендә болай ди: "Рәхмәт итеп Аллаһ биргән малда саранлык кылучы кешеләр уйламасыннар саранлыклары үзләренә файда, дип. Бәлки саранлыклары үзләренә начарлыктыр, саранлык белән җыйган маллары тиздән Кыямәт көнендә муеннарына чорналыр. Җирдәге вә күкләрдәге байлык Аллаһныкы бит һәм Аллаһ сезнең кылган эшләрегездән хәбәрдар" (Ногмани тәфсиреннән). Бу аять – саран кеше хакында. Без үзебезгә сорау бирергә тиешле. Бәлки, зәкят чыгарырга малыбыз җитмидер? Тик гошер сәдакасын бирергә күпләребезнең мөмкинчелеге бар. Аллаһы Тәгалә "Тәүбә" сүрәсенең 60 нчы аятендә: "Сәдакалар - фәкыйрьләргә, мескеннәргә, әмир тарафыннан куелган зәкят җыючыларга, вә зәкят өчен исламга күңелләре өлфәт хасыйл иткән кешеләргә: тоткында булган кешеләргә, бурычын түләргә көче җитмәгән бурычлы кешеләргә, ислам дине өчен Аллаһ юлына һәм малсыз калган мосафирларгадыр, шул күрсәтелгән урыннарга бирмәк Аллаһтан фарыз ителде. Аллаһ белүче вә хөкем итүче" (Ногмани тәфсиреннән). Югарыда санап кителгән җирләргә биргәндә генә аның әҗере була. Башка җиргә эләксә исраф була. Чөнки Аллаһы Тәгалә аңа кая бирергә икәнлеген күрсәтте. Шул сәбәпле, гошер сәдакасын мәчет-мәдрәсәләргә, бигрәк тә дини уку йортларында белем алучыларга бирү хәерлерәк. Ни өчен аны мәдрәсәләрдә укучы шәкертләргә бирү өстенрәк соң? Чөнки җыеп алынган уңышны бер генә кешегә бирсәң, аның череп-бозылып исраф булуы бар. Шуңа күрә, күп кенә дин галимнәре раславынча, аны мәдрәсәгә бирү хәерлерәктер. Рәсүлебезнең (с.г.в.) сәхабәсе Гомәр (р.г.) бер вәгазендә сәхабәләргә шундый сүз җиткерә: "Бөтен дөнья малын бер кашыкка тутырып кулыма бирсәләр, мин аны динне өйрәнүче бер шәкертнең авызына каптырыр идем", – ди. Шулай итеп, хәтта Гомәр (р.г.) дә гошер малын мескен-мохтаҗларга бирү хакында түгел, ә бәлки шәкертләргә тапшыру турында аңлатып китә. Бу, әлбәттә, безгә зур үрнәк. Бүгенге көндә, әлхәмдүлилләһ, мәчетләребез каршында мәдрәсәләр уңышлы гына эшләп килә. Гошер сәдакасын дини уку йортларында укучы шәкертләргә бирү күпкә әҗерлерәк булыр.

***Нияз САБИРҖАНОВ***

# Казанда троллейбус пассажирларын "шәһидләр һәм шәһидәләр"дән сак булырга чакыралар



Түбәндәге игъланнар җәмәгать транспортында пәйда булган.

Башкалабызда "Экстремизмга юл юк!" дигән айлык үтә. Барлык мәчетләрдә дә 2004 елда Бесланда һәлак булганнарны искә алып, дога кылалар, ә дини уку йортларында тематик лекцияләр үткәрелә. Җәмәгать транспорты хезмәткәрләре дә әлеге айлыктан читтә калмады. Мәсәлән, Казан троллейбусларын инде айдан артык "шәһидләр һәм шәһидәләр"дән сак булырга чакыручы игъланнар "бизәп" тора.

Листовкалар пассажирларны әйләнә-тирәдәгеләргә карата уяу булырга, үз-үзен үтерүче "шәһид яки шәһидәләр"нең "сезнең гомерегез өчен куркыныч ниятләре булу мөмкинлеге" хакында кисәтә. Игълан буенча, гражданнар аларны, мәсәлән, түбәндәге билгеләр буенча таный ала: "кара төстәге ябык кием".

Әлеге игъланнар бар кешегә дә ошап бетми. Исламда "шәһид" термины дингә ышанучыларга карата, хәтта бала тапканда үлгән хатын-кызларга һәм газаплы үлем белән үлгәннәргә карата да кулланыла.

"Шәһид" сүзенең мәгънәсе христианнардагы "газапланучы" сүзенә дә якын тора.


– "Газапланучы"лар да, шәһидләр дә террорчылардан һәм бандитлардан аермалы буларак, җинаятьче була алмый, - ди бу игъланнардан канәгать булмаган халык.

– Әлеге игъланнар кешеләр өчен, аларның куркынычсызлыгы өчен, игътибарлы булсыннар өчен языла. Безнең беркемне дә үпкәләтәсебез килми, мин үзем татар кешесе һәм ислам динен тотам. Гадәттә террорчылар шундый кыяфәттә күренгәч, нишлисең?! Ә "шәһид" сүзенең "террорчы" мәгънәсендә кулланылуы бездән генә тормый, – ди Казандагы "Метроэлектротранс" муниципаль унитар предприятиесенең эксплуатацияләү буенча генераль директор урынбасары Илмар Мөхәммәтдинов.

Предприятие дә мөселманнарга каршы бармаска һәм җәмәгать транспортындагы листовкаларда язылган "шәһид һәм шәһидәләр"не "террорчы" сүзенә алмаштырырга булды.

***Максим МИЛОСЛАВСКИЙ, kp.ru сайтыннан алынды***

# Сафлыгымны туйга кадәр югалттым...



**Мин сафлыгымны үзем кияүгә чыгарга җыенган, яраткан кешем белән югалттым. Ләкин безнең туебыз әти-әниләр арасында аңлашылмаучанлыклар килеп чыгу һәм безнең талашулар аркасында булмый калды. Минем әти-әнием эшләгән гөнаһларымны белми. Мин Аллаһтан да, киләчәк тормышымнан да куркам. Хәзер минем белән ни булып бетәр, әйтә алмыйм...**

***Дин белгече җавабы:***

– Иң беренче чиратта, шуны әйтәсем килә: әгәр дә сез дин ничек куша, шулай эшләгән булсагыз, бу мәсьәләләрдән чыгу юлын табарга мөмкин иде. Яшьләргә (ярәшкәннәргә дә) якын мөнәсәбәтләр генә түгел, хәтта әти-әниләре яки башка якын туганнары – мәхрәмнәреннән башка аулакта гади аралашу да тыелган. Әгәр дә барысын да төзәтергә теләгегез һәм мөмкинлегегез булса, ягъни, әгәр дә сезнең арада хисләр, мөнәсәбәтләр бетмәгән икән, аны яратканлыгыгызны, аннан башка яши алмавыгызны әти-әниегезгә әйтергә һәм булган хәлне ничек тә булса белгертеп, ахыр чиктә, егетнең әти-әнисе белән сөйләштерүгә ирешүне киңәш итәм. Әгәр дә сезнең мөнәсәбәтләр чарасыз икән, бер дә кәефегезне төшермәгез. Эшләнгән гөнаһларыгыз өчен тәүбә итегез һәм Аллаһы Тәгаләдән ярдәм сорагыз. Хакыйкатьтә исә, барлык эшләр дә Тудыручыбыз Аллаһ тарафыннан эшләнә. Әгәр дә Аллаһы Тәгалә теләсә, Ул сезгә әлеге егетегездән дә яхшырагын насыйп итәр. Шулай ук, пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) түбәндәге хәдисе бар: "Сезнең һәркайсыгыз хата кыла, ләкин мактауга, үзенең хатасын танып, аны төзәтергә омтылганнарыгыз лаектыр".


***Психолог фикере:***

– Бу еш күзәтелә торган күренеш. Әлеге мәсьәлә шактый четерекле һәм аңа шәхси якын килүне таләп итә. Төп карар сезнең тарафтан булырга тиеш: булачак ирегезгә булган хәлне сөйләргәме яки аны яшерергә тырышыргамы? Кызганычка каршы, барлык ир-егетләр дә мондый хәлне адекват рәвештә кабул итәргә әзер түгел, ләкин кабул итә алсалар да, киләчәк тормышта сезне тынычлыкта калдырачаклары искәрмә булып тормый. Аңлаучы ир-егетләр дә бар, ләкин алар үзләре дә гөнаһсыз түгел һәм дөрес адымнарга баручан.

Сезнең өчен иң мөһиме Аллаһы Тәгаләнең гафу итүе, ә Ул үзенең колларына Мәрхәмәтле. Аннан ярдәм сорагыз һәм киләчәктән курыкмагыз, барысы да Аллаһы Тәгаләдән. Шунысы мөһим: кылган хаталарны киләчәктә кабатламаска, гөнаһлардан сакланырга кирәк.

***Җавап islam.ru сайтыннан алынды***

# "Бибинур"дагы бабай хаҗга җыена...



"Бибинур" кинофильмында бабай ролен башкарган Насыйх Фазылрахмановның быелгы хаҗ юлламасының ярты бәясен Мамадыш муниципаль районы җитәкчесе Анатолий Иванов түләячәк.

Мәгълүм булганча, "Бибинур" фильмы Татарстандагы Мамадыш районының Алгай авылында кинога төшерелде. Анда Мамадышта яшәүче Насыйх әфәнде дә катнашты. Үзенең ролен әйбәт кенә башкарып чыкканы өчен район башлыгы аны изге җирләргә сәфәр кылып кайту юлламасы белән бүләкләде.

Район мөхтәсибе Илһам хәзрәт Миңнегалиев сөйләвенчә, Анатолий Петрович ел саен районда күренекле эш башкарган өч кешегә хаҗ кылырга ярдәм итә, дип яза tatar-islam.ru сайты. Ул шулай ук быел райондагы авылларда авыз ачу мәҗлесләрен үткәрү өчен дә ярдәм кулы сузган.

Анатолий Иванов бу төбәктә православие, керәшен бәйрәмнәрен оештыру өчен дә бар көчен куя.

***intertat.ru сайтыннан алынды***

## Казанда намаз вакытлары

| Көн | Иртә | Кояш | Зәвәл | Икенде | Ахшам | Ястү | Кыйбла | Көн оз. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 10 сен | 04:31 | 06:04 | 12:41 | 17:06 | 19:15 | 20:47 | 13:28 | 13:11 |
| 11 сен | 04:34 | 06:06 | 12:41 | 17:04 | 19:13 | 20:44 | 13:28 | 13:06 |
| 12 сен | 04:36 | 06:08 | 12:40 | 17:02 | 19:10 | 20:41 | 13:27 | 13:02 |
| 13 сен | 04:38 | 06:10 | 12:40 | 16:59 | 19:07 | 20:38 | 13:27 | 12:57 |
| 14 сен | 04:40 | 06:12 | 12:40 | 16:57 | 19:05 | 20:35 | 13:27 | 12:53 |
| 15 сен | 04:43 | 06:13 | 12:39 | 16:55 | 19:02 | 20:32 | 13:27 | 12:48 |
| 16 сен | 04:45 | 06:15 | 12:39 | 16:53 | 18:59 | 20:29 | 13:27 | 12:44 |

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №4 (101) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер-верстка:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 дәнә. **Заказ:** Е-504
**Газета бушлай таратыла.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
**Бастыруга кул куелды: 9 сентябрь, 11.00 сәгать.**
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.
Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**